КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 10 ноябрь г.Казань № 860

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем төзү турында» 2015 ел, 24 октябрь, 803 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем төзү турында» 2015 ел, 24 октябрь, 803 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 4 декабрь, 919 нчы; 2016 ел, 13 гыйнвар, 5 нче; 2016 ел, 18 февраль, 102 нче; 2016 ел, 26 октябрь, 783 нче; 2017 ел, 6 июнь, 346 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем турындагы нигезләмәнең 1.1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре күпюнәлешле муниципаль берәмлегендә яңа инвестицион проектларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү һәм (яки) төзекләндерү чараларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы чыгымнарын финанслашу турында 2015 елның 25 сентябрендәге 06-22-55 нче, 2016 елның 11 августындагы 06-22-13 нче һәм 2017 елның 5 октябрендәге 06-22-23 нче килешүләр (алга таба – Килешү, Чаллы моношәһәре) нигезендә төзелде.»;

әлеге карар белән расланган Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

«Челны Холод» ачык акционерлар җәмгыяте генераль директоры Газилҗан Галимҗан улы Шакирҗановны (килешү буенча);

«ЧЕЛНЫ-ХЛЕБ» акционерлар җәмгыяте генераль директоры Рафаэль Сөләйман улы Юнысовны (килешү буенча);

«Булгарпиво» ачык акционерлар җәмгыяте генераль директоры Руслан Рифкать улы Якушевне (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\860.docx